КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 31 март г.Казань № 298

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары эшчәнлегендә мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдалану, мәгълүмат системаларын һәм мәгълүмат-телекоммуникация инфраструктурасын планлаштыру, булдыру, үстерү, модернизацияләү, эксплуатацияләү чараларын координацияләү тәртибе турында» 2015 ел, 30 май, 387 нче карары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары эшчәнлегендә файдаланыла торган Татарстан Республикасы мәгълүмат системаларын булдыру, модернизацияләү һәм (яки) сатып алу буенча проект заявкасына, аларның чараларын планлаштыруга һәм тормышка ашыруга эксперт бәяләвен үткәрү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары эшчәнлегендә мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдалану, мәгълүмат системаларын һәм мәгълүмат-телекоммуникация инфраструктурасын планлаштыру, булдыру, үстерү, модернизацияләү, эксплуатацияләү чараларын координацияләү тәртибе турында» 2015 ел, 30 май, 387 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 12 октябрь, 740 нчы; 2018 ел, 12 сентябрь, 772 нче; 2019 ел, 18 март, 189 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары эшчәнлегендә файдаланыла

торган Татарстан Республикасы мәгълүмат системаларын булдыру, модернизацияләү һәм (яки) сатып алу буенча проект заявкасына, аларның чараларын планлаштыруга һәм тормышка ашыруга эксперт бәяләвен үткәрү тәртибенә, 2.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«2.3. Татарстан Республикасының Цифрлы трансформацияләү үзәге проект заявкасын алган көннән 20 эш көне эчендә проект заявкасына эксперт бәяләмәсен үткәрә һәм аның буенча бәяләмә формалаштыра.

Проект заявкасына эксперт бәяләве түбәндәге максатлар белән үткәрелә:

проектны гамәлгә ашыруның максатчанлыгын һәм кирәклеген билгеләү;

Татарстан Республикасының булдырыла торган мәгълүмат системаларының чамалана торган нәтиҗәлелеген билгеләү;

проектның Россия Федерациясенең бер яки берничә илкүләм проекты максатларына, шулай ук Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатларына туры килүен билгеләү;

проектның Татарстан Республикасының стратегик максатларына, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы икътисады, социаль өлкәсе һәм дәүләт идарәсе тармакларын цифрлы трансформацияләү өлкәсендәге стратегияне раслау турында» 2021 ел, 18 август, 748 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы икътисады, социаль өлкәсе һәм дәүләт идарәсе тармакларын цифрлы трансформацияләү өлкәсендәге стратегиягә туры килүен билгеләү;

проектны гамәлгә ашыруга җибәрелә торган Татарстан Республикасы бюджеты акчасын нәтиҗәле сарыф итүне тәэмин итү;

мәгълүмат технологияләрен куллану юлы белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыру;

Татарстан Республикасында мәгълүматлаштыру чараларын планлаштырганда һәм тормышка ашырганда бердәмлекне һәм комплекслылыкны тәэмин итү;

Татарстан Республикасының файдаланыла торган мәгълүмат системалары, шул исәптән мәгълүмат-коммуникация технологияләре, мәгълүмат-телекоммуникация инфраструктурасы бер-берсенә туры килү.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин